ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяга:

а) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы идарә органнары – халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең эшчәнлеген координацияләү өчен төзелә торган органнар.»;

б) түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

«Әлеге Законда кулланыла торган башка терминнар һәм төшенчәләр «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон) билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.»;

2) $8^1$ статьяның өченче абзацында «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

3) 10 статьяның унҗиденче абзацында «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

4) 16 статьяның беренче өлешендә «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

5) 19 статьяда:

а) беренче өлешнең беренче абзацында «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «федераль» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 74-ТРЗ